КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 8 октябрь г.Казань № 908

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 апрель, 237 нче; 2015 ел, 15 апрель, 255 нче; 2015 ел, 18 май, 354 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 848 нче; 2016 ел, 11 июль, 470 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 876 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәгълүмат системасы – бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат үзәге турындагы нигезләмә нигезендә мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге;»;

3.3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 4.4 пунктындагы җиденче абзац нигезендә алына торган мәгълүматлар яки гариза бирүче тапшырган документларда әлеге Тәртиптә каралган шартлар үтәлүне раслый торган мәгълүматлар булмау;»;

4.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Гариза бирүченең әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе әлеге пунктның җиденче абзацы нигезендә алына торган белешмәләр, шулай ук гариза составында тапшырыла торган түбәндәге документлар нигезендә билгеләнә:»;

6.5 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин